МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.10.2016 Казан шәһәре № 339

Авыл җирлегенә грант бирү турында шартнамә формаларын һәм гранттан файдалану турында финанс хисабын раслау хакында

«Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 августындагы 614 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар бирү буенча республика конкурсында җиңүчеләргә җиңүчеләргә фантлар күчерү өчен боерам:

1. Кушымта итеп бирелә торган формаларны расларга:

авыл җирлегенә грант бирү турында шартнамә;

грантны файдалану турында финанс хисабы.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны икътисад министры урынбасары Н.А.Таркаевага йөкләргә.

Министр А.А. Здунов

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 28 октябрендәге 339 номерлы боерыгы белән расланды

Форма

Авыл җирлегенә грант бирү турында ____ номерлы
шартнамә

Казан шәһәре «___» ___ 201__ ел

Нигезләмә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы икътисад министры Здунов Артем Алексеевич исеменнән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык), бер яктан, һәм Устав нигезендә эш итүче башлык _________________ исеменнән Татарстан Республикасы __________________ муниципаль районы ________________ авыл җирлеге (алга таба – Грант алучы), икенче яктан, алга таба бергә «Яклар» дип аталучылар, «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 августындагы 614 номерлы карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Шартнамәне (алга таба – Шартнамә) төзеделәр:

1. Шартнамә предметы

1.1. Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсы йомгаклары буенча Грант алучыга акча түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә күчерелә (алга таба – Грант).

2. Грант бирү күләме һәм шартлары

2.1. Грант күләме ________________ сум тәшкил итә.

2.2. Грант Татарстан Республикасы бюджетыннан Грант алучы хисабына күчерелә һәм Грант алучы тарафыннан бары тик турыдан-туры авыл җирлеге тормышын тәэмин итү объектларының матди-техник базасын ныгытуга, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итүгә һәм торак пунктларны тышкы төзекләндерүгә һәм Грант алучының социаль әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итүгә генә тотыла.

3. Министрлыкның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Министрлык Грант алучының Шартнамә нигезендә үзенә йөкләнгән бурычларын үтәвен контрольдә тота.

3.2. Министрлык Грант алучыдан Грантны куллануга кагылышлы финанс һәм башка документларны соратып алырга хокуклы.

3.3. Грант алучы алган Грантны сарыф итүгә кагылышлы документлар тапшырмаган очракта, грантны максатка ярашсыз сарыф иткән очракта, шулай ук дөрес булмаган яки ялган документлар биргән очракта, Министрлык Грант алучыга Шартнамәне вакытыннан алда өзү турында хәбәрнамә җибәрү юлы белән Шартнамәне берьяклы тәртиптә өзәргә хокуклы.

4. Грант алучының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Грант алучы Грант алу хокукына ия.

4.2. Грант алучы Грантны бары тик Шартнамәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән максатларда гына куллануны тәэмин итәргә тиеш. Шул ук вакытта Грант алучы Грант акчаларын тотканда чыгымнар сметасын Министрлык белән килештерә.

4.3. Грантның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында, Грант алучы Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында (http://mert.tatarstan.ru/) Министрлык тарафыннан урнаштырылган Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Грантны куллану турында хисап тапшырырга тиеш.

4.4. Шартнамәнең 3.3 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне алганнан соң, Грант алучы утыз көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә Грант суммасын кире кайтарырга тиеш.

4.5. Грантлар түләүгә бирелгән акчалар, Грант түләүгә бирелгән акчалардан максатка ярашсыз файдаланган һәм (яисә) дөрес булмаган хисап биргән очракта, Татарстан Республикасы бюджеты керемenә 60 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

4.6. Грант алучы тарафыннан Грантны кире кайтару өчен билгеләнгән срокны бозганда, Министрлык Шартнамәнең 4.4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына Грантны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кире кайтару буенча чаралар күрә.

5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар закон нигезендә җаваплы.

6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Шартнамә имзаланган мизгелдән үз көченә керә һәм Яклар тарафыннан Шартнамә буенча барлык йөкләмәләре тулысынча үтәлгәнгә кадәр гамәлдә була.

6.2. Шартнамәгә теләсә нинди үзгәрешләр, өстәмәләр язма рәвештә төзелгән һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлдә була.

6.3. Шартнамә белән җайга салынмаган мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җайга салына.

6.4. Шартнамә Якларның килешүе буенча, суд карары буенча яки Шартнамәдә каралган шартлар барлыкка килгән очракта вакытыннан алда өзелергә мөмкин.

6.5. Шартнамә буенча барлык бәхәсләр Яклар тарафыннан Министрлык урнашкан урындагы судка мөрәҗәгать итү юлы белән хәл ителә

.

6.6. Грант алучы Шартнамәгә кул куюы белән Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан аны Грант алучының Грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүләр үткәрүгә ризалыгын белдерә

.

6.7. Шартнамә тигез юридик көчкә ия 3 нөсхәдә төзелде, 2 нөсхәсе Министрлык өчен, 1 нөсхәсе Грант алучы өчен.

7. Якларның адреслары һәм реквизитлары

| МИНИСТРЛЫК: | ГРАНТ АЛУЧЫ: |
|---|---|

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы<br>420021, ТР, Казан шәһәре, Мәскәү ур., 55 Банк Милли Банк бүлеге Татарстан Республикасы Казан шәһәре, БИК 04920500,<br>к/с -<br>р/с 40201810900000000002<br>алучы: Татарстан Республикасы буенча ФКИ (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, ЛБ007020002- МинЭкон)<br>ИНН 1655141501<br>КПП 165501001<br>ОГРН 1071690045129<br>ОКПО 82318720<br>ОКВЭД 75.11.21 | Татарстан Республикасы ______________ муниципаль районы_________ авыл җирлеге |
| Татарстан Республикасы икътисад министры | Татарстан Республикасы _________. муниципаль районы__________ авыл җирлеге башлыгы |
| ___________________/ Здунов А.А./ | ___________________ / / |

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 28 октябрендәге 339 номерлы боерыгы белән расланды

Форма

Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар бирү буенча республика конкурсында җиңүченең Гранттан файдалану турында ФИНАНС ХИСАБЫ

Моның белән авыл җирлегенә грант бирү турында _____ елның ___ _________ ____ номерлы Шартнамә нигезендә бирелгән Грантның Татарстан Республикасы муниципаль районы авыл җирлеге тормышын тәэмин итү объектларының матди-техник базасын ныгытуга, авыл җирлегендә урнашкан торак пунктларны социаль инфраструктура һәм тышкы төзекләндерү объектлары белән тәэмин итүгә һәм Татарстан Республикасы авыл җирлегенең башка социаль әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итүгә тотылуын раслыйм.

| Чаралар, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр исеме, аларны үткәрү вакыты, урыны һәм катнашучылар (башкаручылар) | Чаралар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтәлешен раслый торган документлар исеме һәм реквизитлары | Барлыгы, сум |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | БАРЛЫГЫ: |

Хисапка тиешле рәвештә расланган дәлилли торган документлар күчермәләре кушып бирелә:

1. 20___ - 20 ____ елларга бухгалтерлык хисаплылыгы __ . _________________1 нөсхәдә _______________________________________биттә
2. Әлеге хисап мәгълүматларын раслый торган документлар ________ биттә __нөсхәдә

Муниципаль районның авыл җирлеге
башлыгы – Грант алучы
ФИА: __________________ Имза _______________
«__»___20__ ___________ел

Муниципаль районның Грант алучы авыл
җирлеге бухгалтеры:
ФИА: __________________ Имза _______________
«__» ___ 20 __ ел